ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы, Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » 01 2022 г. № 1

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым (бер мәртәбә түләүләр) акчаларын җыю тәртибен» раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 28 апрелендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 9.10.2020 ел, № 7 карары белән кабул ителгән Нигезләмәсе нигезендә, һәм 2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә үзара салым (бер тапкыр түләү) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә 2021 елның 11 декабрендәге 1 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:
- әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын (бер мәртәбә түләүләрен) җыю тәртибен;
- әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, Гражданнарга үзара салым акчаларын (бер мәртәбә түләнә торган түләүләрне) түләү турында белдерүнамә (хәбәрнамә) бланкын .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

1 нче кушымта
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы
поселогы
Башкарма комитеты
карарына
17.01.2022 ел № 1

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым (бер мәртәбә түләүләр) акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Урыссу шәһәр тибындагы поселогы гражданнарының үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләнә торган түләүләрне) җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү гражданнар җыенында катнашуга һәм алар тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 2022 елның 15 мартына кадәр срокта гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән (бер тапкыр түләнә торган түләүләрдән) азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгән затлар;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары;
в) Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр;
г) 1,2 төркем инвалидлары, балачактан инвалидлар;
д) 80 яшьтән өлкәнрәк затлар;
е) Чернобыль АЭСында авария ликвидаторлары һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку рәвешендә белем алучы студентлар өчен үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) акчалары - 200 сум күләмендә билгеләнә.

5. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләү (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Гражданнарга үзара салым акчасын (бер тапкыр түләнә торган түләүләрне) түләү турында хәбәрнамә бланкында гражданнарның үзара салымын (бер тапкыр бирелә торган түләүләрен) күчерү өчен түләү реквизитлары, үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләү) суммасы тулы яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымын (бер тапкыр бирелә торган түләүләрен) түләгәндә алынган акчалар Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең (Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы) шәхси счетына керә.

7. Гражданнарның үзара салымы (бер тапкыр түләнә торган түләүләре) акчаларын түләү физик затлар поручениесе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты кассасы аша яисә https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчалар күчерү юлы белән башкарыла .

8. Гражданнарның үзара салым акчасын (бер тапкыр түләнә торган түләүләрне) түләүләре фактын раслау булып гражданнарның үзара салым акчаларын (бер мәртәбә

түләнә торган түләүләрне) түләүләре турында белдерү кәгазьләре (извещения), приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Гражданнарның билгеләнгән вакытка түләнмәгән үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) акчалары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы
поселогы
Башкарма комитеты
карарына
17.01.2022 ел № 1_

Гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләнә торган түләүләрен) түләүләре турында
белдерү кәгазе (уведомление) № ______

Түләүченең Ф.И.А.и.: ________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________________
_________________________________________________________________нигезендә
Сезгә түбәндәге срокка кадәр _____________ түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру өчен үзара салым (бер мәртәбә түләнә торган түләүләр) акчасын
______ сум күләмендә
түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк :
Банк получателя БИК ____________________________________
Сч. № ____________________________________________
Б/С _____________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК _____________________________________________________
ОКАТО _________________________________________________
Түләүнең билгеләнеше_______________________________________________________
______________________________________________________________________________
Җитәкче __________________ ____________________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)
**кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - -**
Гражданнарның _____ сум күләмендә үзара салым акчаларын (бер тапкыр бирелә торган түләүләрне) түләүләре турында белдерү кәгазе (уведомление).
Түләүченең Ф.И.А.и.
_________________________________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Кабул итеп алды "___" ________________ 20___ ел
________________________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, кәгазь төпсәсе (корешок) Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетында тутырыла һәм анда калдырыла.